Әзһәр Габиди

Кошчыгым



Әзһәр Габиди

Кошчыгым

Художнигы В. Е. БУЛАТОВ

ҚАЗАН
ТАТАРСТАН ҚИТАП НӘШРИЯТЫ
1981

Җәйге кич

Җәйге кичтә ак болытлар
Аллана,
Куакларда сандугачлар
Моңлана.
Җир өстендә көмеш чыклар
Җемелди,
Кыекларда күгәрченнәр
Гөрелди.
Бабайлар да гәп коралар
Болдырда,
Кешнәп куя яшь колыннар
Болында.
Көйли хезмәт җырын кырда
Башаклар,
Бу җырга без барыбыз да
Гашыйклар.
Күреп шушы гүзәллекне
Ташый хис,
Нинди шаулы, нинди ямьле
Җәйге кич!



Көтү кайта

Тау артына
Кояш батты,
Җир өстенә
Эңгер ятты,
Авылымда
Шатлык артты —
Урам тулып
Көтү кайтты.

Сөтләр ага
Чиләкләргә,
Нәниләрне
Бүләкләргә.

Әй тәмле дә
Сыер сөте,
Аннан килә
Чәчәк исе,
Болын исе,
Тугай исе,
Муллык исе,
Бәхет исе!



Яз—рәссам

Яз шундый гүзәл,
Яз шундый күркәм,
Җиргә тукый ул
Ямь-яшел келәм.

Һич йөртмәсә дә
Үзендә энә,
Келәм өстенә
Чәчәкләр чигә.

Чиккән чәчәге
Төрледән-төрле,
Бар аның күге,
Бар зәп-зәңгәре.

Бар кызылы да,
Бар сарысы да,
Сылудан сылу
Алар барсы да.

Яз шундый гүзәл,
Яз шундый уңган.
Яз кебек оста
Рәссам булам.

Кошчыгым

Сылу кошчыгым,
Һич тик тормыйсың,
Иртәсен-кичен
Сузып җырлыйсың.



Әллә син мине
Күрми дисеңме?
Матур җырыңны
Сөйми дисеңме?

Синең җырыңны
Оттым бит инде,
Әнигә шуны
Җырлыйм бит инде.

Шуңа әнием
Иркәли, сөя,
Яратып мине:
— Кошчыгым! — дия.

Үсәсе килә

Яңгыр явып торганда да
Мин өйгә кермим,—
Буйга тизрәк үсү өчен
Яланбаш йөрим.

Ипине дә үсү өчен
Ашыйм май ягып,
Чәйне дә эчәм, шикәрне
Күп итеп салып.

Тик аларның берсенең дә
Файдасын сизмим,—
Иптәшләрдән озын булып
Һич тә тиз үсмим.

Ә абыйлар, апалардай
Үсәсем килә,
Бакчадан инде мәктәпкә
Күчәсем килә!

Көз

Көзне кырыс дип сөйлиләр,
Ул шундый шаян икән:
Каен, имәннәрнең шәлен
Сарыга манып киткән.

Миләш-сылуга гашыйктыр —
Алтын алкалар таккан,
Аның белән серләшергә
Болынга учак яккан.

Әллә буявы аз булган,
Әллә ул кабаланган? —
Урмандагы чыршы, нарат
Маныймый яшел калган.

Гаҗәп иртә

Кичен генә көзге җилләр,
Без уйнап йөргән чакта,
Яфракларны куып йөрде
Урамнардагы чатта.

Иртән буяучы абыйлар
Безнең турдан үткәнме?
Кызык булсын өчен җирне
Акка буяп киткәнме?

Белдем инде: без йоклагач
Кыш бабай килеп җиткән,
Безгә чаңгы шуар өчен
Ак карлар түшәп киткән.

Котырма, буран...

Котырма, буран,
Тын торсын урам,
Күммә син юлны:
Туңмасын кошлар —
Канатлы дуслар.
Аңла син шуны.

Котырма битәр,
Сиңа чик җитәр,
Ләйсәннәр үтәр,
Игеннәр үсәр,
Гөлләнер тугай;
Биек-биектә —
Зәп-зәңгәр күктә
Җыр сузар тургай.



Ҡарлардан сырган
Юрганың белән
Масайма, январь,
Яшел хәтфәле,
Гөлле-чәчәкле
Сылу май да бар!

Кар бабайга ни булган?

Ник ясамаска кар бабай?
Әйдә, ясыйбыз!
Ягез, ярышып карыйбыз —
Өлгер кайсыбыз?

Күмәк эш тауны күчерә —
Тиз тоттык эшне;
Ун-унбиш минутта әзер
Булды кар кеше.

Марат алып килде кишер,
Ә мин — чүгендер,
Нургали табып китерде
Кайдандыр күмер.

Куйдык танауны кишердән,
Күзне — күмердән;
Колакны — мин алып килгән
Пар чөгендердән.

Чәч ясарга да таптык без
Бик җайлы чара:
Нигә аптырап торырга
Себерке барда!!

Сүтеп аның чыбыкларын
Чәч итеп тездек,
Кар кешебез матур чыккач
Шатландык, көлдек.

Уйный торгач, киемебез
Манма су булды.
Салкын да тешли башлады
Аякны, кулны.

Бер-бер артлы таралыштык
Өйләребезгә,
Кар кеше янында безнең
Калмады кем дә.

Кәҗә бәтиләре аны
Харап иткәннәр,
Танау белән колакларын
Ашап киткәннәр.

Һич кенә таба алмаган
Саклану юлын —
Онытканбыз икән аның
Ясарга кулын...

Яз сөңгеләре

Март иртәсендә абыем
Тыштан шатланып керде.
Ул көлә-көлә әнигә:
— Безгә яз килгән! — диде.

— Каян беләсең? — дип аңа
Әнием сорау бирде,
Абый аңа: — яз кыекка
Сөңгеләр элгән! — диде.

Хәйләсен тапкан

Вәли дә хәзер
Зур булып үскән,
Авызга капмый
Бармагын күптән.

Шук малай Вәли
Хәйләсен тапкан —
Бармак урнына
Бер конфет капкан.

— Бармакны,— ди ул,—
Энем суырсын,—
Ә миңа,— ди ул,—
Конфеты булсын.

Уракчы ажаган

Яз буе җәй көтеп
Сабыры калмаган,
Камчысын уйната
Офыкта аҗаган.

Беләмсез, дусларым:
Аҗаган уйнавы —
Игеннәр урырга
Урагын кайравы.

Әллә малай чагы булмаган?

Нәрсә генә уйнасаң да
Һич ошамый бабайга,
Безне исәпләп йөри ул
Бер җилкуар малайга.

— Әллә ни итеп күрдегез
Хоккей белән футболны.
Шар сугып, туп типкән булып
Йөрү уен булдымы?

Шашка, шахмат уйныйм диеп
Утырасыз баш ватып,
Уен булдымы тормагач
Бөтен кеше шаккатып.



Эстафеталы уйныйм дип,
Әйтәм бик ишәсез,— ди,—
Куян куган эт шикелле
Әлсерәп төшәсез,— ди.

Кызык итеп шул бабайга
Нәрсә уйнарга тагы?!
Булырмы безнең уенны
Берәр ошаткан чагы?!

Белмим, үзе яшь чагында
Нәрсә генә уйнаган?
Әллә аның беркайчан да
Малай чагы булмаган?!

Нигә ул мине көтми?

Кич җиттеме, син, әбекәй:
— Ят, йокың килә,— дисең,
Ни төслерәк була соң ул,
Гел миңа күрсәтмисең.

Килгәнен көтеп алмагач,
Әллә инде чит итә?
Нигә, әби, мин торганчы
Ул өйдән чыгып китә?

Бик күрәсем килә аны,
Ник шуны белми икән?
Өйгә бикләп куяр диеп
Әллә ул шүрли микән?

Сораулар белән әбисен
Йөдәтә торгач, Иркә,
Аруыннан күзен йомып,
Тәмле йокыга китә.

Коңгызлар

Дөрләп янган учаклардан
Сибелгәндәй очкыннар,
Төнге һаваны яктыртып
Оча «утлы» коңгызлар.

Әнә шул «утлы» коңгызның
Берсе чирәмгә кунды,
Тотып алыр идем инде —
Пешерер сыман кулны.

Шулай да җиңеп куркуны
Коңгызны учка алдым,
Пешермәгәч ул кулымны
Шундый гаҗәпкә калдым.

Алтын ут

Урман яна,
Болын яна,
Тугай яна
Алтын утта;
Ул ут яна бакчаларда,
Бөтен йортта.

Урман яна,
Болын яна,
Тугай яна
Алтын утта;
Бу ут күмә табигатьне
Нур, шатлыкка.

Урман яна,
Болын яна,
Тугай яна
Алтын утта;
Көннән-көн ул ялкынлана —
Көз походта.

Урман яна,
Болын яна,
Тугай яна
Алтын утта;
Җир янмасын, сүз бирмик
без
Кылыч, тупка!

ЭЧТӘЛЕК

Җәйге кич 3
Көтү кайта 4
Яз — рәссам 4
Кошчыгым 5
Үсәсе килә 6
Күз 7
Гаҗәп иртә 7
Котырма, буран... 8
Кар бабайга ни булган? . . 10
Яз сөңгеләре 11
Хәйләсен тапкан 11
Уракчы аҗаган 12
Әллә малай чагы булмаган? 12
Нигә ул мине көтми? . . . 13
Коңгызлар 14
Алтын ут 16

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

Габидуллин Азгар Самигуллович

ПТИЧКА

(на татарском языке)

Редакторы *К. Котдусова*
Художество редакторы *Г. Трифонов*
Техник редакторы *В. Галкина*
Корректоры *Р. Раскулова*

ИБ № 2415

Наборга бирелде 9/II-1981 ел. Басарга кул куелды 29/VI-1981 ел. Гарнитура литературная. Печать высокая. Формат $60\times90^{1}/_{16}$. Учетно-изд. таб. 1,1. Басма таб. 1,0. Усл. кр. отт. 1,3. Типография кәгазе № 1. Тираж 10.000. Заказ Н-92. Бәясе 5 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.

С(Тат)2
Г12

Г $\frac{70801-212}{М132(03)-81}$ 174—81

© Татарстан китап нәшрияты. 1981.

5 тиен